# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишбатман авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2025 елның 6 марты №9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 6 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2024 елның 22 ноябрендәге 6 номерлы карарга (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә ризамы?:

1) карардагы «500 сум» сүзләрен «23000 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«(2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру)».

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 31 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 кеше кертелде, бу 64,5% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 20 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2025 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Бишбатман авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1

төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан тыш, 23000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

4. Алынган акчаларны, 2 пунктны яңа редакциядә бәян итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

5. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М. Саттаров